| АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 07.10.2025 1613 **КАРАР**

2025 елның җәйге чорында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын оештыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары, Россия Федерациясенең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Россия Федерациясендә пляжлардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 30 сентябрендәге 732 номерлы боерыгы нигезендә, Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау һәм имин ялын оештыру максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында оештырылган ял урыннары исемлеген (1 нче кушымта);

1.2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы пляжын карап тоту кагыйдәләрен (2 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына:

2.1. оешмалар белән контрактлар төзү эшен оештырырга:

- пляжда һәм су объектларында ял итү урыннарында коткару һәм медицина пунктларын карап тоту һәм эшен оештыру буенча хезмәтләр күрсәтергә;

- су объектларында кешеләрнең ял итү урыннарын һәм төпләрен водолазлар ( су астында эшләүчеләр) ярдәмендә тикшерергә;

- пляжны ачу алдыннан суга һәм туфракка беренчел анализлар үткәртергә.

2.2. 2025 елның 1 июленнән алып 31 августына кадәр пляжда һәм су



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 1 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

объектларында оештырылган ял итү урыннарында җәмәгать коткару посты оештырырга, 08.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр пляжда коткаручыларның эш режимын билгеләргә;

2.3. кирәк булган очракта, тиешле мәгълүмат такталары урнаштырып, коену өчен су объектларыннан файдалануны, кече суднолардан, шул исәптән гидроциклардан һәм башка техника чараларыннан файдалануны чикләү яки туктатып тору турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә;

2.4. суда үз-үзеңне тотуның куркынычсызлык кагыйдәләре һәм Алабуга муниципаль районының су объектларында су коенуны чикләү турында халыкка мәгълүмат җиткерүне оештырырга;

2.5. Алабуга муниципаль районы пляжында һәм су янында оештырылган ял итү урыннарында коткару һәм медицина постларын карап тоту буенча хезмәт күрсәтүгә контрактның үтәлешен, коткаручыларның эшен контрольдә тотуны оештырырга.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына:

3.1. 2025 елның 1 июленә кадәр җаваплы оешмалар тарафыннан пляжны һәм су янында оештырылган ял итү урыннарын коену сезонына әзерләү буенча кирәкле чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

3.2. 2025 елның 1 июленә кадәр территориягә туры китереп, «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 15 отряды» Федераль дәүләт казна учреждениесенең 101 нче янгын сүндерү-коткару бүлеге, «Алабуга үзәк хастаханәсе» сәламәтлек саклау дәүләт автономияле учреждениесе һәм Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының Гражданнарны яклау идарәсе белән берлектә пляжны һәм су янында оештырылган ял урыннарын кабул итү буенча район комиссияләре төзергә.

4. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторына, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы мәгариф идарәсенә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторына:

4.1. 2025 елның 1 июленә кадәр Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә учреждениеләрендә су объектларында балаларның үз-үзләрен тоту кагыйдәләре, ачык суда куркынычсызлык чаралары, батучыларга ярдәм итү алымнары һәм ысуллары буенча балалар һәм ата-аналар белән әңгәмәләр һәм инструктажлар үткәрергә;

4.2. балаларны сәламәтләндерү һәм мәктәп яны лагерьларының эш планында ачык суда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен һәм куркынычсызлык чараларын аңлату чараларын күздә тотарга.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәм:

5.1. Алабуга районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенә:

5.1.1. муниципаль пляжда куркынычсызлыкны һәм хокук тәртибен саклауны оештырырга, шул исәптән рөхсәтсез сәүдә итүне, табигатьне саклау турындагы законнарны бозуны, спиртлы эчемлекләр эчү очракларын кисәтүне тәэмин итәргә, хокук бозучыларга карата законнар нигезендә чаралар күрергә;



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 2 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

5.1.2. су коену сезоны чорында муниципаль пляжны полиция нарядлары тарафыннан патрульлек итүне: көн саен 15.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә, ял һәм бәйрәм көннәрендә: 09.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр оештырырга;

5.2. 2025 елның 1 июленнән 31 августына кадәр чорда «Алабуга үзәк хастаханәсе» сәламәтлек саклау дәүләт автономияле учреждениесенә район халкының күпләп ял итү урыннарында беренче медицина ярдәме күрсәтү буенча халык арасында аңлату эшләре алып баруны оештырырга.

6. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифасын вакытлыча башкаручы А.А. Томилин

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5D5B832C0D4CC8A96C405A04F5061337
Владелец: Томилин Андрей Александрович
Действителен с 25.09.2024 до 19.12.2025

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның __ ______ №____ карарына 1 нче кушымта

2025 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының су объектларында оештырылган ял урыннары исемлеге

| N т/б | Атамасы | Урнашу урыны | Районы: | Җаваплы учреждение |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Алабуга шәһәре пляжы | Кама елгасы, Шишкин урамы | Алабуга | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |

2025 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының су объектларында оештырылган ял урыннары исемлеге

| N т/б | Атамасы | Пляжны яки су объектларында оештырылган ял итү урынын әзерләү һәм карап тоту эшләренең заказ бирүчесе | Пляжларда һәм су объектларында оештырылган ял итү урыннарында коткару һәм медицина постларын булдыру, пляжларның төпләрен водолазлар ярдәмендә тикшерү, лаборатор тикшерү үткәрү эшләренең заказ бирүчесе |
|---|---|---|---|
| 1 | Алабуга шәһәре пляжы | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 4 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның __ ______ №____ карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы пляжын карап тоту кагыйдәләре**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Пляж дип массакүләм ял итү һәм су коену өчен файдаланыла торган, гражданнар ялы өчен махсус җиһазландырылган яр участогы булган су объекты яки участогы санала.

1.2. Һәр пляжның паспорты булырга тиеш, анда аның атамасы һәм характеристикасы күрсәтелә.

1.3. Пляжны әзерләү, аларны карап тоту һәм куллану куркынычсызлыгын тәэмин итү Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә.

1.4. Пляжны әзерләүне һәм карап тотуны Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, ә санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәүне санитария - эпидемиология күзәтчелеге органнары контрольдә тота.

1.5. Пляжда сезонны ачу, файдалану санитар-эпидемиологик күзәтчелек органнарыннан тиешле рөхсәт алганнан соң гамәлгә ашырыла.

1.6. Пляжның җәйге чорга әзерлеге, кагыйдә буларак, 1 июньгә кадәр тәэмин ителергә тиеш.

## 2. Пляжның эшен оештыру

2.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Башкарма комитеты пляж эшчәнлеген тәэмин итү максатларында түбәндәгеләрне:

- пляжны карап тоту һәм үсеше буенча эшләрне финанслауны күздә тота;
- һава шартлары нигезендә пляжлардан файдалану вакытын билгели (кагыйдә буларак, 1 июньнән 31 августына кадәр).

## 3. Пляждан файдалану өчен җаваплы затның төп бурычлары

3.1. Пляждан файдалану өчен җаваплы затка түбәндәге бурычлар йөкләнә:

- пляжны сезонга үз вакытында әзерләү;
- пляжның тиешенчә эшләвен тәэмин итү (медицина хезмәте күрсәтү, хокук тәртибен саклау, сәүдә итү, санитария иминлеге һ.б.).

## 4. Пляж өчен территорияләр сайлауга таләпләр



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 5 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27

4.1. Пляж өчен сайлап алына торган территорияләргә түбәндәге таләпләр куела:

- су объектындагы суның сыйфаты һәм территориянең санитар торышы ГОСТ 17.1.5.02-80 «Табигатьне саклау. Гидросфера. Су объектларын рекреацияләү зоналарына карата гигиена таләпләре»нә туры килү;

- су объекты төбенең рельефы куркынычсыз (чокырлар, куе булып үскән суүсемнәре, очлы ташлар һ.б. булмау) булу;

- уңайлы гидрологик режимы (су агымының тизлеге 0,5 м/с артмау, су әйләнмәләре, су өсте тигезлегенең кискен тирбәлешләре булмау) булу.

4.2. Пляж зонасы, җирле шартларны исәпкә алып, порт корылмаларыннан, шлюзлардан, агынты сулар агызу урыннарыннан, башка пычрану чыганакларыннан ерак урнашырга тиеш.

4.3. Пляж сәнәгать предприятиеләренең санитар-яклау зоналарыннан читтә һәм әйләнә-тирә мохитне пычрату һәм тавыш чыганакларына карата җилле якка урнаштырылырга тиеш.

## 5. Пляжга таләпләр

5.1. Пляж территориясенең кирәкле мәйданын исәпләгәндә бер кешегә кимендә 8 кв. м нормадан чыгып исәпләнә. Балалар секторы мәйданы бер балага кимендә 4 кв.м дан да ким булмаган норманы күз алдында тотып исәпләнә.

5.2. Коену зонасы чикләре тиешле тану билгеләре белән күрсәтелә.

5.3. Балалар секторында коену зонасы төбе 40-50 см тирәнлектәге сөзәк авышлык белән булырга тиеш, әмма коену зонасы тирәнлеге 70 см артмый.

5.4. Пляжда «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчәргә яраклы суга һәм халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак биналарга, җитештерү биналарыннан, иҗтимагый биналардан файдалануга, санитария-эпидемиягә каршы (профилактика) чараларны оештыруга һәм үткәрүгә карата санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.1.3684-21 санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә эчәргә яраклы сулы фонтаннар, киенү-чишенү кабиналары, бәдрәфләр, чүп контейнерлары һәм савытлары куела.

5.5. Җәмәгать бәдрәфләреннән коену урынына кадәрге ераклык кимендә 50 метрны тәшкил итәргә, әмма 200 метрдан арттырылмый. Бәдрәфләр урнаштырганда агынты суларны чистарту корылмаларына бүлеп җибәрүне тәэмин итә торган канализация каралган булырга тиеш. Канализация булмаган очракта, су үткәрми торган чокырлар булдыру яки биобәдрәфләрдән файдалану зарур.

5.6. Пляжда медицина пункты, полиция, күзәтү вышкасы һәм хәбәр итү системасы белән коткару станциясе, пляж администрациясе өчен бүлмәләр булдырыла.

Терәк баганалар (щитлар) янында 2 метрдан да ким булмаган биеклектәге коткаручы вышкасы урнаштырыла.



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 6 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

5.7. Ял итү урыннары һәм аның тирәсендәге территорияләр көн саен җыештырыла, чүп чыгарыла.

5.8. Чүп контейнерлары ял итү зонасыннан читтә, уңайлы килү юллары булган бетонланган мәйданчыкларга урнаштырыла.

5.9. Пляж системалы рәвештә һәм очраклы пычранудан, агынты сулардан саклана.

5.10. Агынты суларны коену өчен файдаланыла торган су объектларына бүлеп җибәрү зарурлыгы булган очракта, аларны агызу җир өслегендәге суларны агынты сулары белән пычранудан саклау кагыйдәләрен үтәгәндә рөхсәт ителергә мөмкин.

5.11. Коену зонасына, коткару хезмәте чараларыннан тыш, башка транспорт чаралары (көймәләр, катерлар, суднолар) белән керү рөхсәт ителми.

5.12. Коену зонасы территориясендә «Хайваннарны коендыру тыела» дигән эчтәлекле аншлаглар эленеп куела.

**Пляжлардан файдалану өчен җаваплы затның бурычлары**

6.1. Пляждан файдалану өчен җаваплы затка түбәндәге бурычлар йөкләнә:

- коену урыннарында коткару хезмәте эшчәнлеген тәэмин итү, шәһәр халкының күпләп ял итү урыннарында янгынга каршы чаралар күрү;

- пляжның су өлешен, тану билгеләрен кулланып, балалар һәм олылар өчен коену зоналарына, шулай ук коену тыела торган зоналарга бүлү;

- ел саен су коену зонасының төбен куе булып үскән суүсемнәреннән чистартуны, пляжга чиста ком сибүне һәм пляж сезоны башланганчы комның өске катламын йомшартуны оештыру;

- пляж милкен саклауны тәэмин итү.

6.2. Пляжда кешеләрнең иминлеген саклау максатыннан Алабуга муниципаль районының Башкарма комитеты түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

6.2.1. Су коену зонасы чикләрендә су объекты акваториясе участогы төбен су үсемлекләреннән, тамырлардан, пыяладан, ташлардан һәм пляжга килүчеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган әйберләрдән водолазлар (су астында эшләүчеләр) тикшерүен үткәрүне һәм чистартуны тәэмин итәргә.

6.2.2. Россия Федерациясе Су кодексының 25 статьясындагы 8 пункты нигезендә раслана торган су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Россия Федерациясендә пляжлардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 30 сентябрендәге 732 номерлы боерыгы нигезендә эксплуатацияләүнең бөтен чорына пляжны таләпләр нигезендә җиһазлауны һәм карап тотуны тәэмин итәргә.

6.2.3. Пляжны эксплуатацияләү чорына пост булдырырга һәм аның эшен тәэмин итәргә.

6.2.4. Пляжда гадәттән тыш хәлләрне һәм вакыйгаларны кисәтү һәм аны булдырмау чараларын үткәрергә.

6.2.5. Ял итәргә килүчеләргә түбәндәге мәгълүматларны җиткерергә:

сигнал флаглары, тавыш белән хәбәр итү, куркынычсызлык билгеләре кую һәм мәгълүмат стендларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән коену һәм пляждан куркынычсыз файдалану мөмкинлеге;

пляжның эш режимы, аның хуҗасы, хезмәт күрсәтүче оешмалар һәм аларның реквизитлары, телефоннары;

кешеләргә беренче ярдәм күрсәтү алымнары һәм суда кешеләр белән бәхетсезлек очракларын профилактикалау чаралары;

агымдагы датага һава торышы фаразы, су һәм һава температурасы;

куркыныч урыннарны, тирәнлекләрне, коткаручыларның урнашу урыннарын күрсәтеп, пляж һәм су коену зонасы схемасы;

авария-коткару хезмәтләре яисә формированиеләре бүлекчәләренең, ашыгыч медицина ярдәме һәм полиция телефон номерлары турында.

6.2.6. Пляжда гадәттән тыш хәлләр һәм вакыйгалар турында ашыгыч оператив хезмәтләргә хәбәр итү.

6.3. Ел саен пляжны эксплуатацияли башлар алдыннан Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының кече суднолар буенча дәүләт инспекциясенең Алабуга районы бүлекчәсенә гариза-декларация җибәрә, аның тәкъдим ителгән үрнәге Кагыйдәләрнеңтәкъдим ителгән үрнәге 1 нче кушымтада китерелгән.

Гариза-декларация Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының кече суднолар буенча дәүләт инспекциясенең Алабуга районы буенча урнашкан бүлекчәсенә гариза-декларациядә күрсәтелгән пляжны эксплуатацияли башлауның планлаштырылган датасына кимендә 30 календарь көн кала тапшырыла. Гариза-декларациягә пляжның проект (эксплуатация) документациясеннән өзекләр теркәлә, алар гариза-декларациядә күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген раслый.

6.4. Гариза-декларацияне тапшыру түбәндәге ысулларның берсе нигезендә гамәлгә ашырыла:

6.4.1. кәгазь чыганакта:

почта элемтәсе аша;

кулдан;

6.4.2. электрон рәвештә:

«Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып;

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Интернет» мәгълүмат ресурслары ярдәмендә.

6.5. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының кече суднолар буенча дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы Алабуга районы буенча бүлекчәсе



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 8 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

вазыйфаи затлары гариза-декларацияләр кергән көннән алып 5 эш көне эчендә аның тутырылуының дөреслеген, шулай ук кушымтада бирелгән документлар тикшерелә. Гариза-декларациядә булган мәгълүматлар дөрес булган очракта, Татарстан Республикасы Алабуга районы буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының кече суднолар буенча Дәүләт инспекциясенең вазифаи затлары теркәлү номерын бирү юлы белән теркәлә.

Теркәү номеры ике өлештән тора.

Номерның беренче өлеше гариза-декларация теркәлгән Россия Федерациясе субъектының кодыннан тора. Номерның икенче өлеше дүрт санлы тәртип номерыннан тора.

6.6. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты адресына ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының кече үлчәмле суднолар буенча дәүләт инспекциясе вазыйфаи заты ул кергән көннән алып 5 эш көне эчендә бирелгән теркәлү номеры турында мәгълүмат белән гариза-декларацияне теркәү турында хәбәрнамә җибәрә. Хәбәрнамә гариза-декларациядә күрсәтелгән ысул белән җибәрелә.

6.7. Гариза-декларациядәге мәгълүмат дөрес җибәрелмәгән очракта, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының кече суднолар буенча дәүләт инспекциясенең Алабуга районы буенча бүлекчәсенә аныклаучы белешмәләр җибәрү кирәклеге турында хәбәр ителә.

6.8. Теркәлгән гариза-декларациядә күрсәтелгән белешмәләр үзгәргән очракта, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтелгән үзгәрешләр турында мәгълүматны гариза-декларацияне теркәүне гамәлгә ашырган Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының кече суднолар буенча дәүләт инспекциясенең Алабуга районы буенча бүлекчәсенә мондый үзгәрешләр башланганнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрә.

6.9. **Пляжда ял итүчеләрнең бурычлары**

6.9.1. Пляжда ял итүчеләр түбәндәгеләргә бурычлы:

6.9.1.1. Билгеләнгән урыннарда гына коенырга.

6.9.1.2. Су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләрне үтәргә;

6.9.1.3. Пляж милкен һәм җиһазларын бозуга юл куймаска;

6.9.1.4. Гадәттән тыш оператив хезмәтләргә, коткаручыларга пляжда булган хәлләр һәм су объектларында гадәттән тыш хәлләр турында мәгълүмат бирергә.

**6.10. Пляжга килүчеләргә тыела**

6.10.1. Коену зонасын һәм пляж территориясен пычратырга һәм чүпләргә;

6.10.2. Пляж җиһазларын һәм коткару чараларын билгеләнү буенча кулланмау;

6.10.3. Кызыл (кара) флаг күтәрелгәндә, бу коену тыелганын аңлата, коену.

6.10.4. Коену зонасының чикләрен билгеләүче буйкаларны чыгып йөзү;

6.10.5. Йөзү өчен билгеләнмәгән предметларда (шул исәптән такталарда,



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 9 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

бүрәнәләрдә, ятмаларда) йөзәргә.

6.10.6. Сигнал калкавычын өзәргә яисә батырырга, коену зонасының чикләрен билгеләүче киртәләрнең урынын үзгәртергә, бу максатлар өчен җайлаштырылмаган корылмалардан суга сикерергә.

6.10.7. Начар күречүләрне йөртүче этләрдән кала, үзләре белән хайваннарны пляжга алып килү;

6.10.8. Әлеге максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарда спорт уеннары уйнау, шулай ук су өстенә су коенучыларны ату, чумдыру һәм басып алу белән бәйле гамәлләрне башкару;

6.10.9. Ялган тревога сигналларын бирү;

6.10.10. Балаларның йөзү күнекмәләре булу-булмауга карамастан, караучысыз калдыру.

## 7. Пляжны куркынычсыз файдалануны оештыру

7.1. Пляждан файдалануны оештыру су, җир, Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясенең халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турындагы законнары таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

7.2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты коену өчен билгеләнгән акватория чикләрен билгеләүне тәэмин итә (алга таба - коену зонасы).

7.3. Коену зонасы чикләрен билгеләү өчен йөзеп йөрүче көнкүреш чүп-чары кебек күренергә мөмкин булган әйберләрне куллану тыела (мәсәлән, шешәләр, канистрлар).

7.4. Балалар һәм йөзә белмәгән кешеләрнең коенуы коену зонасының махсус билгеләнгән өлешендә рөхсәт ителә.

7.5. Йөзү күнекмәләре булмаган затларның, хроник авырулары булган кешеләрнең һәм балаларның суда булу куркынычы турында хәбәр итә торган сары төстәге сигнал флагы кулланып, Алабуга муниципаль районы пляжының Башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда коену чикләнергә тиеш:

җилнең тизлеге 5,5 - 7,9 метр секундка һәм дулкыннарның биеклеге 1,2 - 1,5 метр булганда;

вакытлыча кыска вакытлы (5 - 7 минуттан артык булмаган) агымнарның тизлеге 0,5 - 0,7 метр секундка булганда.

7.6. Пляжның Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан, кешеләрнең суда булу куркынычы турында хәбәр итә торган кызыл (кара) төстәге сигнал флагы кулланып, түбәндәге очракларда коену тыелырга тиеш:

шторм турында кисәтү алганда;

җилнең тизлеге 7,9 метр/секундка һәм дулкыннарның биеклеге 1,5 метр булганда;

секундына 0,5 метрдан артыграк тизлектәге агымнар булганда;

су биеклеге тәүлегенә 0,2 метрдан артыграк тизлек белән күтәрелгәндә;

су объекты нефть продуктлары, сәнәгать, авыл хуҗалыгы һәм коммуналь предприятиеләрнең агып төшүче сулары, су транспорты судноларының



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 10 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

көнкүреш агып төшүче сулары, хуҗалык-көнкүреш һәм льяль сулары белән пычранганда;

дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы вәкаләтлесе су объектының санитария кагыйдәләренә һәм су объектын су коену өчен халык сәламәтлеге өчен куркынычсыз файдалану шартларына туры килмәве турында санитар-эпидемиологик нәтиҗә алганда.

7.7. Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты, бәхетсезлек очракларын кисәтү һәм суда бәла-казага дучар булган кешеләргә ярдәм күрсәтү максатларында, су коену тыелуына карамастан, пляжның билгеләнгән эш вакытында коткаручылар дежурлыгы белән коткару посты (алга таба - пост) эшен оештыра, пляж эше 08:00 сәгатьтән 20:00 сәгатькә кадәр.

Пост коткаручыларның коену зонасын күзәтүне һәм аларның пляжга килүчеләрнең үлеменә яки җәрәхәтләнүенә китерергә мөмкин булган хәлләргә реакциясен тәэмин итәргә тиеш.

Постта кулланылган коткару чаралары сәнәгать җитештерүе булырга һәм сертификатланган булырга тиеш.

Коткаручылар кунакларның иминлеген даими күзәтеп торырга, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Россия Федерациясендә пляжлардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 30 сентябрендәге 732 номерлы боерыгының IV бүлеге таләпләрен бозу очракларын кисәтү чараларын күрергә тиеш.

7.8. Пляжда балаларның ял итүен һәм сәламәтләнүен оештыру вакытында коткаручы белән коткару көймәсе балалар коену зонасының тышкы ягыннан 2 метрдан ерак булмаска тиеш.

Йөзәргә өйрәтү урыннарында өйрәтелүчеләрнең иминлеген тәэмин итүче чаралар булырга тиеш (аерым алганда, йөзү такталары, коткару боҗралары, коллар, йөзү өчен ярдәм итүче каешлар, электромегафоннар).

## 8. Коткару постын урнаштыру һәм җиһазлау кагыйдәләре

8.1. Коткару посты су кулланучы тарафыннан куела.

8.2. Коткару посты су кулланучы тарафыннан расланган графикка туры китереп эшләнә.

8.3. Коткару посты түбәндәге көчләр һәм чараларны үз эченә ала:

«Коткаручы» дип язылган көймә – 1 данә;

коткару боҗрасы - 3 данә;

коткару жилеты - 5 данә;

«Александровның коткару очы» дигән ярдәм күрсәтү чарасы - 2 данә;

тавышны көчәйтү чарасы (электромегафон) - 1 данә;

Кече суднолар өчен компакт җыелма якорь -1 данә;

кызыл тәреле ак флаг - 2 данә;

багор (тимер ыргак) - 2 данә;



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 11 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

су өстендә бәхетсезлек очрагында беренче ярдәм күрсәтү өчен медикаментлар җыелмасы белән санитар сумка яки аптечка - 1 комплект
су өстендә бәхетсезлек очракларыннан ярдәм күрсәтүгә - 1 комплект;
янгынга каршы щит - 1 комплект;
җиңел су асты водолаз чаралары (ласты, маска, трубка) - 2 комплект.
пляж полосасының озынлыгы 50 метрга кадәр булганда ике коткаручы.



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 12 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының карары белән
расланган кагыйдәләргә 1 нче кушымта,
«__» ________20__ел

**Тәкъдим ителгән үрнәк**

**Гариза-декларация**

1. Пляж турында мәгълүмат

Россия Федерациясе субъекты

Пляжның адресы (урнашу урыны

Торак пункт (төре,
исеме

Пляжда коену өчен каралган килүчеләр саны

Пляжның яр буе сызыгы озынлыгы

Коену зонасының мәйданы

Пляж сайтының мәгълүмати-
телекоммуникация челтәрендә адресы
телекоммуникация челтәре
"Интернет" (булган очракта)

Агымдагы елда пляжның эшли башлау планлаштырылган көне

2. Гариза-декларацияне теркәү турында хәбәр итүне 3 бүлектә күрсәтелгән адрес буенча җибәрүне сорыйм:

электрон почта адресына, почта адресына, телефонга
почта

3. Пляжның хокук иясе турында мәгълүмат:

3.1. Юридик зат



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 13 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27

Юридик затның исеме
(оештыру-хокук формасы)
тулы атамасы

Төп дәүләт теркәү номеры

Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры/Исәпкә кую сәбәбе кодысы_______________________________________

Почта адресы

Электрон почта адресы (булган очракта):
булу/ булмавы

лефон (булган очракта

3.2. Шәхси эшкуар
Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
булу/ булмавы

Шәхси эшмәкәрнең төп дәүләт теркәве номеры (ОГРНИП)

Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры

Аерым шәхси счетның иминият номеры

Документ атамасы, сериясе һәм номеры
(шәхеснең)
бирелү вакыты

Телефон (булган очракта)

Электрон почта адресы (булган очракта):
булганда):булганда):

Яшәү урыны буенча теркәлү адресы:
яшәү урыны буенча яки вакытлыча тору урыны буенча

3.3. физик затның
Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
булу/ булмавы



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 14 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27

Аерым шәхси счетның иминият номеры

салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (булган очракта)

Документ атамасы, сериясе һәм номер (шәхескә) бирелү вакыты

Яшәү урыны буенча теркәлү адресы:

Телефон (булган очракта)

Электрон почта адресы (булган очракта):

4. Әлеге декларация белән пляжда су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләрен үтәү раслана:

| | ӘЙЕ | ЮК | Проект/ эксплуатация документациясе каралмаган |
|---|---|---|---|
| 4.1. Су коену зонасы чикләрендә су үсемлекләреннән, тамырлардан, пыялалардан, ташлардан һәм пляжга килүчеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы әйберләрдән суга сикерү тикшерүе һәм төбен чистарту үткәрелгәнме? | ☐ | ☐ | |
| 4.2. Су коену зонасының чикләре билгеләнгәнме? | ☐ | ☐ | |
| 4.3. Балалар һәм йөзә белмәгән кешеләр өчен су коену зонасында участок каралганмы? | ☐ | ☐ | ☐ |
| 4.4. Пляж территориясендә һәм акваториясендә урнаштырылган күперләр, траплар, төшү юллары, саллар һәм манаралар спецификацион эксплуатация шартларында аларга йөкләнешне күтәрә алырлык ныклыкка һәм тотрыклылыкка ияме? | ☐ | ☐ | ☐ |
| 4.5. Пляжның яр полосасында коткару чаралары урнаштырылганмы? | ☐ | ☐ | ☐ |
| 4.6. Ял итүчеләрне түбәндәге мәгълүматлар белән тәэмин итү: | ☐ | ☐ | |
| 4.6.1. Сигнал флаглары, тавыш белән хәбәр итү, куркынычсызлык билгеләре кую һәм мәгълүмат стендларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән коену һәм пляждан куркынычсыз файдалану мөмкинлеге бармы? | ☐ | ☐ | |



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 15 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.6.2. Пляжның эш режимы, аның хуҗасы, хезмәт күрсәтүче оешмалар һәм аларның реквизитлары, телефоннары бармы? | ☐ | ☐ | |
| 4.6.3. Кешеләргә беренче ярдәм күрсәтү алымнары һәм суда кешеләр белән бәхетсезлек очракларын профилактикалау чаралары бармы? | ☐ | ☐ | |
| 4.6.4. Агымдагы датага һава торышы фаразы, су һәм һава температурасы күрсәткече бармы? | ☐ | ☐ | |
| 4.6.5. Куркыныч урыннарны, тирәнлекләрне, коткаручыларның урнашу урыннарын күрсәтеп, пляж һәм су коену зонасы схемасы бармы? | ☐ | ☐ | |
| 4.6.6. Авария-коткару хезмәтләре яисә формированиеләре бүлекчәләренең, ашыгыч медицина ярдәме һәм полиция телефон номерлары бармы? | ☐ | ☐ | |
| 4.7. Пляж телефон һәм тавыш көчәйткеч элемтә чаралары белән җиһазландырылганмы? | ☐ | ☐ | ☐ |
| 4.8. Пляжда коткаручыларның дежурлыгы белән коткару посты булдырылганмы? | ☐ | ☐ | |
| 4.9. Коену зонасында кечкенә судноларны прокатка бирү пунктларын урнаштыруга чикләүләр каралганмы? | ☐ | ☐ | |

5. Әлеге декларациядә күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы, шулай ук шәхси белешмәләрне эшкәртүгә (шәхси белешмәләрне җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, төгәлләштерүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхессезләндерүгә, блоклауга, юкка чыгаруга, шулай ук шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) ризалык пляждан файдалануымны раслыйм.

Датасы: "__" ________ 20__ ел (имза)

М.У. (юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен (булган очракта)



Документ создан в электронной форме. № 1613 от 07.10.2025. Исполнитель: Каретина К.Д.
Страница 16 из 17. Страница создана: 08.10.2025 13:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 1613 от 07.10.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 08.10.2025 13:27

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Томилин А.А. | | Подписано<br>08.10.2025 - 14:59 | - |